РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 сентябрь 2018 Буа шәһәре № 267/ИК-п

2018-2020 елларга
Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районының
көндәшлеген үстерү программасын
раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Конкуренцияне саклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасының Буа муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының көндәшлеген үстерү программасы Нигезләмәсен расларга (Кушымта).
2. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырылырга һәм мәгълүмати-телекоммуникацион «Интернет» челтәрендә ТР Буа муниципаль районының рәсми сайтында (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе Р.Р. Кәмәртдинов

ТР Буа муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 12 сентябрендәге
267/ИК-п номерлы
карарына кушымта

# 2018-2020 елларга
# Татарстан Республикасы
# Буа муниципаль районы
# көндәшлеген үстерү программасы

Буа шәһәре

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының көндәшлеген үстерү программасы» (алга таба - Программа) |
| Норматив хокукый нигезе | - Россия Федерациясе Президентының «Көндәшлекне үстерү буенча дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре турында» 2017 елның 21 декабрендәге 618 номерлы Указы;<br>- «Көндәшлекне саклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 5 сентябрендәге 1738-р номерлы Карары. |
| Программаның муниципаль заказчысы | Буа муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның төп төзүчесе һәм башкару буенча координаторы | Буа муниципаль районы Башкарма комитетының Территориаль үсеш бүлеге |
| Программаның максаты | 1. Хуҗалык итүче субъектларның ярышучанлыгы өчен тигез шартлар тәэмин итүче механизмнар булдыру аша, Буа муниципаль районы икътисадының нәтиҗәлелеген һәм көндәшлелеген күтәрү.<br>2. Куллану товарлары һәм хезмәтләренә бәяләрне төшерү, аларның үтемлелеген һәм сыйфатын үстерү исәбенә, Буа муниципаль районы халкының тормыш сыйфатын һәм дәрәҗәсен күтәрү. |
| Программа бурычлары | 1. Эшмәкәрлек эшчәнлеген башларга һәм алып барырга комачаулаучы һәм катлауландыручы административ киртәләрне киметү. |

| | |
|---|---|
| | 2. Базарда катнашучыларның эшчәнлеге өчен кирәкле логистик, сәүдә, энергетика, мәгълүмати инфраструктураны булдыруга ярдәм итү һәм үстерү, һәм алардан файдалану өчен тигез шартлар тәэмин итү.<br>3. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү. |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2018-2020 еллар |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре һәм социаль-икътисади нәтиҗәлелек күрсәткечләре | Максатчан күрсәткечләр:<br>- Белем бирү хезмәтләре базарында дәүләтнеке булмаган сектор өлеше үсеше;<br>- Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан уңай хәл ителгән заявкалар саны үсеше һәм яңа сәүдә объектлары ачылышы;<br>- агросәнәгать паркы резидентлары саны үсеше;<br>- сәүдә предприятиеләрендә товар әйләнеше күләме артуы;<br>- Туристлар агымының узган елгка карата саны артуы;<br>Программаны тормышка ашыру шулай ук Программаны тормышка ашыру нәтиҗәлелегенең түбәндәге социаль-икътисади нәтиҗәләренә ирешергә мөмкинлек бирә:<br>- көндәшлекле мохитне үстерү;<br>- белем бирү хезмәтләре базарында дәүләтнеке булмаган (муниципаль булмаган) секторда көндәшлекне үстерү өчен шартлар булдыру һәм яңа сәүдә ноктлары ачу, бу бюджетның барлык дәрәҗәләренә дә салым түләүләрен арттыруга китерәчәк;<br>- эшмәкәрлек эшчәнлегенең тотрыклы үсеше өчен шартлар тудыру;<br>- сыйфатлы авыл хуҗалыгы продукциясе белән сәүдә итүне тәэмин итү. |

| | |
|---|---|
| Финанслау чыганаклары | Кабул ителгән муниципаль программалар нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының консолидацияләнгән бюджеты мөмкинлекләреннән чыгып. |
| Чаралар планын тормышка ашыру механизмы | Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе 2018 елның 11 гыйнварындагы 4-п номерлы карары белән расланган, 2018-2020 елларда Буа муниципаль районында көндәшлекне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планы («Юл картасы») нигезендә. |

**Эчтәлек**

Кереш ........................................................................................................ 6
1 бүлек. Программа чишәргә юнәлдерелгән мәсьәләләрнең характеристикасы ........................................................................................ 7
1.1. Балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре базары ........................................ 7
1.2. Ваклап сатуның хезмәтләр базары ................................................................ 9
1.3. Авыл хуҗалыгы продукциясе базары.......................................................... 11
1.4. Мәдәният өлкәсендәге хезмәтләр базары ................................................... 12
1.5. Медицина хезмәтләре базары...................................................................... 13
1.6. Торак-коммуналь хуҗалык базары.............................................................. 14
1.7. Элемтә хезмәтләре базары ........................................................................... 13
1.8. Азык-төлек продукциясе базары.................................................................. 13
2 бүлек. Тормышка ашыруның нәтиҗәләре һәм максатчан индекаторлар ............ 15
3 бүлек. 2018-2020 елларга Буа муниципаль районында көндәшлекне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планы («Юл картасы»)................................... 16

Кушымта. Программаны тормышка ашыру буенча чаралар планы.

## Кереш

Буа муниципаль районындагы чынбарлык икътисади вәзгыятьтән һәм базарда катнашучыларның икътисади мәнфәгатьләреннән чыгып формалаштырылган Программа, көндәшлек мохитен үстерүдә өстенлекләрне, максат һәм бурычларны түбәндәге товар һәм хезмәтләр төбәк базарларында билгели:

1. балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре базары;
2. ваклап сату хезмәтләре базары;
3. туристик хезмәтләр базары.

Әлеге Программада түбәндәге төп төшенчәләр файдаланыла:

- аерым базарда көндәшлек мохите ул – әлеге базарда табыш алу мөмкинлекләрен ачыклау һәм файдалануда хуҗалык итүче субъектларның мөмкинлеген билгеләүче факторлар җыелмасы;

- алга киткән көндәшлекле мохит – көндәшлекле, нәтиҗәле һәм инновацияле бизнесның кулланучыларның икътисади мәнфәгатьләрен яклау белән ярашуын, базар бәяләрен мөмкин кадәр түбән билгеләү, шул ук вакытта аеруча нәтиҗәле предприятиеләрнең озак вакытка финанс тотрыклылыгын тәэмин итүче уңай факторлар өстенлек иткән мохит. Көндәшлек үсеш алганда хәтта базардагы бердәнбер эшмәкәр дә бәяләр сәясәтен тормышка ашырганда пәйда булырга мөмкин көндәшләрне исәпкә алырга мәҗбүр;

- көндәшле сәясәт ул – хуҗалык итүче субъектлар ярыша алсын өчен шартлар тәэмин итү максатында, һәм шулай ук икътисади нәтиҗәле ысул белән гражданнарның товар һәм хезмәтләргә ихтыяҗын канәгатьләндерергә этәргеч биргән мохит тудыру өчен, дәүләт тарафыннан тормышка ашырыла торган эзлекле чаралар комплексы.

Әлеге Программа базар катнашучыларына көндәшлекле көрәштә тигез шартлар тудыру аша Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы икътисады үсешендә уңай динамиканы тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Көндәшлекле мохитне үстерүнең төп нәтиҗәләре булып, Россия икътисадының нәтиҗәлелеген һәм көндәшлелеген күтәрү, предприятиеләрне модернизацияләү, халыкның тормыш сыйфатын күтәрү торачак.

## 1 бүлек. Программа чишәргә юнәлдерелгән проблемаларның характеристикасы

### 1.1 Балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре базары

Бүгенге белем бирү хезмәтләре базары төрле рәвештәге һәм форма милегендәге белем бирү учреждениеләре бергәлегеннән гыйбарәт. Соңгы елларда белем бирү хезмәтләре базары үсешенә «Мәгариф» өстенлекле илкүләм проекты, мәгарифне модернизацияләү комплекслы проекты этәргеч бирде, алар ярдәме белән белем бирү процессын финанслаучы матди база шактый яхшырды. Гамәлдәге норматив база белем бирү учреждениеләрен хезмәтне конкрет кулланучы өчен ярышучанлык шартларына куя. Бу, беренче чиратта, гомум белем бирү, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләренә кагыла.

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ тәрбия эшчәнлеге системасында өстәмә белем бирү системасы мөһим урынны били. Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре челтәрен саклау һәм үстерү баланың шәхесен һәрьяклап үстерүдә кирәкле шарт булып тора, балаларның мәшгульлеге аша хокук бозуларны кисәтү буенча эшчәнлекне камилләштерергә булыша.

Өстәмә белем бирү системасы беренче сыйныфтан башлап, өлкән сыйныфта укучыларга кадәр, төрле яшьтәге төркемнәргә шөгыльләнергә мөмкинлек тудыра.

Заманча өстәмә белем бирү системасы балага сайлап алу өчен иҗади эшчәнлекнең күп төрләре буенча белем бирү программаларын тәкъдим итәргә әзер. Районда 6 өстәмә белем бирү учреждениесе эшли (2 учреждение ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында («ТР Буа шәһәренең Мәктәптән тыш эшләр үзәге» Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе, «ТР Буа шәһәре Балалар сәнгать мәктәбе» Муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе) һәм 4се башка ведомстволар карамагында), аларда 3613 бала шөгыльләнә (2016 елда – 3537). Балаларны өстәмә белем бирү белән колачлау 78,2% тәшкил итә, 2016 елда – 76%. Медицина кабинетлары саны – 7. Сәламәтлеккә ярдәм итүче мәктәпләр – 33, алтын дәрәҗәдәге – 3, көмеш дәрәҗәдәге – 13.

Мәктәпләрдә һәм мәктәптән тыш учреждениеләрдә хәрби-патриотик берләшмәләр уңышлы эшли. Буа шәһәренең академик Р.З.Сәгъдиев исемендәге гомуми урта белем бирү мәктәбе базасындагы Мәктәптән тыш эшләү үзәгенең «Патриот» берләшмәсе, «Рюкзачок» берләшмәсе эшчәнлек алып бара.

«Мәгариф һәм сәламәтлек» программасын тормышка ашыру кысаларында, үсеп килүче буынның сәламәтлеген ныгыту, балаларны һәм яшүсмерләрне системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә җәлеп итү, аларда сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча эшләр башкарыла. Мәктәптәге спорт секцияләрендә 2000нән артык укучы шөгыльләнә, бу – районда укучыларның гомуми санының 43% тәшкил итә. Район укучылары арасында бигрәк тә киң таралган спорт төрләре: баскетбол, волейбол, футбол, милли көрәш, бадминтон, чаңгы, хоккей, җиңел атлетика.

Өстәмә белем бирү учреждениесе буларак, спорт мәктәбе үз-үзеңне камилләштерүгә, белем туплау һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру иҗатына, һөнәри үзбилгеләнүгә, физик интеллектуаль һәм әхлакый сәләтләрне үстерүгә, мөмкинлекләреңә карап спорт уңышлары дәрәҗәсенә ирешергә ярдәм итү бурычын тота.

**Төп проблемалар:**

- түгәрәкләргә йөрүче укучыларның саны кимүе (моның сәбәбе – кайбер берләшмәләр актив эшләүдән туктау сәбәпле, укучылар түгәрәктә яки секциядә шөгыльләнү белән кызыксынмый башлады);

- өстәмә белем бирү өлкәсендәге шәхси оешмаларда өстәмә белем хезмәтләрен алучы балаларның проценты бик түбән;

- белем бирү учреждениеләрен, шул исәптән дәүләтнеке булмаганнарын төзегәндә җир бүлеп бирүдә кыенлыклар;

- белем бирү процессын тәэмин итүгә чыгымнарның бәясе югары булуы;

- матди-техник базаның канәгатьләндерерлек булмавы.

**Бурычлар:**

1. Өстәмә белем бирү хезмәтләре базарының дәүләтнеке булмаган (муниципаль булмаган) секторында көндәшлекне үстерү өчен шартлар тудыру.

2. Өстәмә белем бирү өлкәсендәге шәхси оешмаларда белем бирү хезмәтләрен алучы балалар санының чагыштырмача исәбен 2020 елга 3% кадәр арттыру.

### 1.2. Ваклап сатуның хезмәтләр базары

2017 елда, беренчел бәяләү буенча, ваклап сатуның әйләнеше 3 миллиард 600 миллион сум тәшкил итте, яки 2014 ел дәрәҗәсенә 109,04%.

Ваклап сатудагы товар әйләнеше күләменең үсеш динамикасы күзәтелә.

Районда 1306 кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты теркәлгән, аларда 239 кече предприятие, 1067 шәхси эшмәкәр икътисади актив эшчәнлек алып бара. Бүген районда тулаем территориаль продуктның 26,3% (Татарстан Республикасында – 25,5%) әлеге секторга туры килә.

Шул ук вакытта районда кече һәм урта бизнес әйләнешенең төп өлеше сәүдә өлкәсендә – 40% артыграк (ТРда – 54%), төзелештә – 36,6% (ТРда – 11%), авыл хуҗалыгында – 10,4% (ТРда – 3%).

Кече предприятиеләрнең күпчелеге кумәртәләп һәм ваклап сату өлкәсенә, шулай ук төзелешкә карый. Әлеге өлкәләр эшмәкәрләрне озак еллар дәвамында җәлеп итеп килә. Бу кече бизнес субъектлары үзләренең бөтен ресурсларын аеруча рентабельле һәм исән калыр өчен мөһим булган эшчәнлек юнәлешләренә тотарга омтылуын күрсәтә.

Районның 35 сәүдә объектына Буа райпосы хезмәт күрсәтә. Районның 40 торак пунктына күчмә сәүдә оештырылган.

Район халкын стационар сәүдә объектлары мәйданы белән фактик тәэмин ителеш 1000 кешегә 454 кв. м тәшкил итә яки 129,3% (норматив буенча 1000 кешегә кимендә 351 кв. м).

Районның җәмәгать туклануы челтәре 36 объектны тәшкил итә.

Район территориясендә ике ваклап сату базары эшли – 1 ял көне эшләүче базар (Буа райпосы тарафыннан), 1 базар көндәлек режимда эшли («Тургай» Сәүдә үзәге). Шулай ук районда 3 сәүдә үзәге бар: «Семейный Бум» Сәүдә үзәге, «Буа» Сәүдә үзәге. 10 элемтә салоны.

Районда фармацевтика эшчәнлеген 20 даруханә тәкъдим итә, шул исәптән 4 ветеринария даруханәсе.

Медицина тармагында 13 шәхси клиника эшли.

2 ветеринария клиникасы бар.

Районда 27 чәчтарашханә исәпләнә. Кием тегү һәм ремонтлау буенча 5 ателье эшли.

Автотранспортка техник хезмәт күрсәтү өлкәсендә районда автомобильләргә техник хезмәт күрсәтү буенча 8 станция эшчәнлек алып бара.

Берничә ел дәвамында районда 2 такси хезмәте уңышлы гына көндәшлек итә.

9 автозаправка һәм газозаправка станциясе исәпләнә.

Шулай ук район территориясендә «Тандер» ЯАЖ (4 «Магнит» кибете), «Агроторг» ЖЧЖ (5 «Пятерочка» кибете), «Бристоль», «РусАлко», «Красное Белое» кебек эре сәүдә челтәрләре үз эшчәнлеген оештырган.

Районның ваклап сату базарында көндәшлекне анализлау түбәндәге проблемаларны ачыклады:

1. Эре сәүдә челтәре компанияләренең бик тиз «кереп урнашуы» сәбәпле, көндәшлекнең көчәюе;

2. Федераль сәүдә челтәре компанияләре товар әйләнешенә җирле товар җитештерүчеләрнең продукцияләрен кертү кыен;

3. Логистика чылбыры булмау, бу – товарның үзкыйммәте артуга китерә.

4. Энергия ресурсларының үзкыйммәте артуы, халыкның сатып алу мөмкинлеге кимүе, кредит ставкаларының артуы, кадрлар җитмәү кебек, кече һәм урта эшмәкәрлеккә тискәре йогынты ясаучы факторларның үсүе.

Гомумән районда ваклап сату базары – югары көндәшлекле базар ул. Әмма вәзгыятьне яхшырту өчен түбәндәге чаралар планын төзергә мөмкин:

1) Сәүдә урыннарын һәм объектларын төзегәндә җир алу өчен киртәләрне киметү.

2) Төзелеш өчен җир алганда нигезсез кире кагуларга юл куймау.

3) Сәүдәне үстерүдә республика (муниципаль) программаларны тормышка ашырганда нәтиҗәлелекнең яңа индикатив күрсәткечләрен кертү – Россия җитештерүчеләренең товарларына сорауны үстерү өчен шартлар тудыру.

4) Азык-төлек товарларына ваклап сату бәяләре динамикасын мониторинглауны башкару.

Соңгы елларда ваклап сату әйләнешен формалаштыру структурасы җитди үзгәрешләргә дучар булды: базарлар өлеше кимеде һәм оештырылган сәүдә бизнесы өлеше үсте, һәм нәтиҗә буларак, аның әһәмиятлелеге артты. Эре сәүдә комплекслары, гипермаркетлар төзелеше күбәйде. Федераль сәүдә челтәрләре («Магнит», «Пятерочка», «Бристоль») ягыннан төбәктә кулланучылар базарының инвестицион җәлеп итүчәнлеге үсте. Шәһәрдә һәм районда федераль сәүдә челтәрләре эшләве шәхси кибетләр саны кимүгә китерде.

Буш сәүдә мәйданнары булгач, әлеге позиция буенча ваклап сатучы кибетләр арасында көндәшлекне киметте. Әмма төрле ташламалар тәкъдим итү, промоакцияләр үткәрү юлы белән сатып алучы өчен көрәш көчәйде. Сәүдә мәйданнарының шактый өлешен ваклап сату кибетләре били, һәм алар күп кенә җитештерүчеләр өчен продукцияне сатуда төп юнәлеш булып тора. Ваклап сату челтәрләренең товар сатып алу сәясәте кулланучыларга үтемле бәяләр буенча тәкъдим ителгән товарларның сыйфаты тотрыклы булуы белән билгеләнә.

**Төп проблемалар:**

- кулланучылар базары өлкәсендә көндәшлекне үстерү проблемасы эшмәкәрлек эшчәнлеге инфраструктурасының канәгатьләндермәгән хәленә бәйле, бигрәк тә финанс хәленә.

- кулланучылар активлыгы төшүе, халыкның керемнәр дәрәҗәсе кимүе, шулай ук инфляция процесслары һәм халыкның күп кредитларда яшәве;

- чималга, эшкәртелгән продуктларга бәяләр белән сату бәяләренең бәйләнеше авыл хуҗалыгы продукциясе (сөт, ит, бодай һәм яшелчә культуралары) җитештерүчеләренең рентабельле хуҗалык алып баруына туры килми.

**Бурычлар:**

1. Ваклап сату өлкәсендә намуслы көндәшлекне үстерү.

2. Авыл хуҗалыгы продукциясе (чимал) һәм эшкәртелгән продуктларга бәяләрне мониторинглау.

3. Җитештерүчеләр, эшкәртүчеләр һәм сатучылар арасында, оештыру-хокукый формасы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативына җавап биргән, кооперация тудыру.

4. Кулланучылар һәм авыл хуҗалыгы кооперацияләре оешмаларына ярдәм итү буенча комплекслы чаралар күрсәтү.

5. Районда урта һәм кече эшмәкәрлекне үстерү.

## 1.3. Авыл хуҗалыгы продукциясе базары

Буа районы икътисадының төп тармагы – авыл хуҗалыгы. Район республиканың 2,9% авыл хуҗалыгы җирләрен файдаланып, аның авыл хуҗалыгы продукциясе күләменнән 4% артыгын җитештерә.

2017 елда тулаем продукция бәясе 4 миллиард 750 мең сумны тәшкил итте, бу үткән елдагы күрсәткеч белән чагыштырганда +5%.

Авыл хуҗалыгы продукциясе күләме шактый артуның төп факторы булып хезмәт җитештерүчәнлегенең дәрәҗәсе тора, ә бу күрсәткеч турыдан-туры хезмәтнең энергия белән коралланышына да һәм нәтиҗәле оештырылуына да бәйле. 2017 елда авыл хуҗалыгы предприятиеләрендә бер эшчегә 1 миллион 970 мең сумлык суммага продукция җитештерелгән.

Районның авыл хуҗалыгында 5 авыл хуҗалыгы предприятиесе һәм 78 крестьян (фермерлык) хуҗалыклары исәпләнә.

Көндәшлекнең гомуми торышы уңай бәяләнә. Шул ук вакытта «Ак Барс» ХК кебек бер эре компания дә бар. Төп административ киртәләр – законнарның тотрыксызлыгы һәм җир участокларына үтеп керүдә кыенлыклар.

Чаралар:

1) Беренче чиратта җирле кече һәм урта товар җитештерүчеләрнең продукциясен сатуны һәм үстерүне тәэмин итүче ярминкә сәүдәсе, авыл хуҗалыгы һәм универсаль базарлар, стационар булмаган һәм мобиль сәүдә, күргәзмә эшчәнлеген үстерүгә булышу, һәм шулай ук эчке һәм тышкы базарларда яңа төр продукцияләрне үткәрү өчен булган җитештерү көчләрен аеруча тулырак файдалану.

2) Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештергәндә яңа технологияләрне һәм башка төбәк һәм илләрнең алдынгы тәҗрибәсен кертүгә ярдәм итү.

3) Авыл хуҗалыгы продукциясе базарында дәүләт ярдәме чаралары турында консультация бирү.

## 1.4. Мәдәният өлкәсендә хезмәтләр базары

Районда әлеге өлкәдә бары тик муниципаль учреждениеләр генә хезмәт күрсәтә, бу түбән көндәшлек турында сөйли. Шәхси бизнес ягыннан мәдәният өлкәсендә эшчәнлеген киңәйтергә планлаштыручылар юк. Административ барьер буларак законнарның тотрыксызлыгын билгеләп була.

Чаралар:

1) Бу базарда лидерлар рәтендәге уенчылар ягыннан көндәшлеккә каршы гамәлләрен киметү.

2) Мәдәният (сәнгать) өлкәсендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итүгә юнәлдерелгән грантлар бирү буенча тормышка ашырылган федераль һәм төбәк программаларын пропагандалау.

**Балалар ялы һәм сәламәтләндерү хезмәтләре базары**

Әлеге базарда уртача дәрәҗәдәге көндәшлек билгеләнә. Көндәшлекне үстерү буенча төп чаралар исәбенә керә: персоналны укыту һәм балаларның ялын тәэмин итүгә һәм аларны сәламәтләндерүгә (балаларның шәһәр читендәге ял һәм сәламәтләндерү лагерьлары, балалар сәламәтләндерү үзәкләре, базалары һәм комплекслары, балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәкләре, махсуслаштырылган (профильле) лагерьлар (спорт-сәламәтләндерү һәм башкалар), каникул вакытларында (тәүлек әйләнәсе яки көндезге тору урыны белән) укучыларның ялын һәм сәламәтләндерелүен оештыруны башкаручы белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган шифаханә-сәламәтләндерү балалар лагерьлары һәм башка оешмалар, лагерьлар, һәм шулай ук социаль хезмәт күрсәтү оешмалары, шифаханә-курорт оешмалары, иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) һәм башка оешмалар карамагында оештырылган балалар хезмәт һәм ял лагерьлары, чатырлар тибындагы балалар лагерьлары, балалар махсуслаштырылган (профильле) лагерьлары, төрле тематик юнәлештәге балалар лагерьлары (оборона-спорт, туристик, экологик-биологик, иҗади, тарихи-патриотик, техник, туган якны өйрәнү һәм башкалар) чыгымнарны киметү.

1) Башка төбәкләр белән хезмәттәшлеккә һәм тәҗрибә уртаклашуга ярдәм итү.

2) Аз керемле гаиләләр өчен республика шифаханәләрендә һәм чит илләрдә балалар ялының үтемлелеген күтәрү.

## 1.5. Медицина хезмәтләре базары

Көндәшлекнең гомуми торышы уңай бәяләнә. Көндәшлекне күтәрү нигездә персоналны укыту һәм продукцияне танытуның яңа ысулларын файдалану белән бәйле, шуңа күрә медицина хезмәтләре базарында көндәшлекне күтәрү өчен түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

1. Медицина хезмәтләрен күрсәтү өлкәсендә башка төбәкләр белән бәйләнешкә керүгә һәм хезмәттәшлеккә булышу.
2. Медицина эшчәнлеген тормышка ашыру өчен рөхсәтләр алу максатында хокукый консультацияләр һәм аңлатмалар бирү.
3. Шәхси клиникалар күрсәткән хезмәтләрнең сыйфатын тикшерүне көчәйтү.
4. Медицина кулланышындагы дару препаратлары базарлары һәм медицина эшләнмәләре базарларының үзара алмашынучанлык принципларында эшләп торуын тәмин итү.
5. Медицина кулланышындагы дару препаратлары базарлары һәм медицина эшләнмәләре (даруханә) базарлары вәкилләренә үзара алмашынучанлык принципларында сатып алучылар сайлавына кыйммәтле категориядән һәм беркадәр арзан аналоглар категориясеннән дарулар тәкъдим итү бурычын йөкләү.

## 1.6. Торак-коммуналь хуҗалык базары

Әлеге базарда түбән көндәшлек билгеләнә. Көндәшлекне үстерү максатында түбәндәге чаралар тәкъдим ителә:

1) Технологик инновацияләргә булышу.

2) Базарның потенциаль катнашучыларына консультация һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү.

3) Уңай тәҗрибәләрне кертү, бенчмаркинг.

**Халыкка социаль хезмәт күрсәтү базары**

Әлеге базарда көчсез көндәшлек күзәтелә. Районда бу базарда дәүләт учреждениеләре эшли.

Чаралар:

1) Халыкка социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүчеләрнең квалификациясен күтәрү.

2) Гражданнарга консультация, мәгълүмати ярдәм күрсәтү.

3) Башка төбәкләрнең уңай тәҗрибәләрен кертүгә булышу.

### 1.7. Элемтә хезмәтләре базары

Көндәшлек торышы уңай бәяләнә.

Чаралар:

1) Эре уенчылар һәм табигый монополияләр эшчәнлегенә дәүләт күзәтчелеге.

2) Базарга яңа катнашучылар чыгуына ярдәм итү.

3) Стартаплар өчен заемнар алуда булышу.

### 1.8. Азык-төлек продукциясе базары

Көндәшлек уртача хәлдә.

Чаралар:

1) Җирле товар җитештерүчеләргә башка төбәкләрнең базарларына һәм эре сәүдә челтәрләренә чыгуда ярдәм итү.

2) Продукция сыйфатын тикшерүне көчәйтү.

3) Аера торган билгесе турында маркировкасы булган («югары сыйфатлы ит», «мәрмәр ит», «хәләл», «кошер ит») продукция җитештерүче яңа базар катнашучыларына булышу.

4) Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына консультация һәм мәгълүмати ярдәм күрсәтү.

Районда «2018-2020 елларга Буа муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү һәм үстерү» муниципаль максатчан программасы кысаларында чаралар тормышка ашырыла.

Программаның төп максаты:

Гражданнарның иркен тормышын үстерү һәм икътисади актив урта класс формалаштыру, районның тотрыклы социаль-икътисади үсешен тәэмин итү, район икътисадында кече бизнесның тоткан урынын арттыру.

Программаның мөһим бурычлары:

1. Бизнесның нәтиҗәле үсешенә комачаулаган норматив-хокукый, административ һәм оештыру киртәләрен бетерү юлы белән уңайлы эшмәкәрлек климатын тәэмин итү;

2. Эшмәкәрлек субъектларының финанс ресурсларына үтеп керү мөмкинлеген киңәйтү, шул исәптән бюджеттан тыш чаралар җәлеп итү аша да;

3. Җиһазлар һәм технологияләр лизингын үстерү;

4. Эшмәкәрлек субъектларына чынлыкта да финанс-милек һәм оештыру-методик ярдәм күрсәтү;

5. Кече бизнесны үстерү инфраструктурасы объектларын булдыру һәм үстерү;

6. Кече бизнесны үстерүнең өстенлекле юнәлешләренә булышу;

7. Эш белән мәшгуль булмаган халыкны кече бизнес өлкәсенә җәлеп итү өчен өстәмә этәргечләр булдыру.

Районда кече һәм урта бизнес үсешенең торышын җитәрлек дәрәҗәдә тотрыклы дип билгеләп була.

Россия Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указын үтәү максатында, Буа муниципаль районы территориясендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк булдырылды, аның эшчәнлеге дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең үтемлегенә һәм сыйфатын арттыруга, хакимият органнары эшчәнлеге турында мәгълүматның ачык булуына юнәлдерелгән.

## 2 бүлек. Тормышка ашыруның нәтиҗәләре һәм максатчан индекаторлар

Программаны тормышка ашырудан көтелгән ахыргы нәтиҗәләр һәм социаль икътисади нәтиҗәлелек күрсәткечләре:

| **Программаның максатлары индекаторлары атамалары** | **Агымдагы күрсәткеч** (2017 ел) | **Максатчан күрсәткечләр** | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **2018 ел** | **2019 ел** | **2020 ел** |
| Шәхси оешмаларда өстәмә белем бирү берләшмәләренә йөрүче балаларның өлеше, %: | 2,4 | 2,6 | 2,8 | 3,0 |
| Кече һәм ерак торак пунктларда ачылган яңа сәүдә объектлары саны, берәмлек: | 3 | 2 | 2 | 2 |
| Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында ачарга кирәкле яңа сәүдә объектлары саны, берәмлек: | 3 | 2 | 2 | 2 |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан яңа сәүдә объектлары ачу турындагы уңай хәл ителгән заявкалар саны, берәмлек: | 2 | 2 | 2 | 2 |
| Агросәнәгать паркы резидентлары саны, берәмлек: | | 5 | 13 | 16 |
| Сату күләме үсеше, %: | 106 | 107 | 109 | 110 |

**3 бүлек. 2018-2020 елларга Буа муниципаль районында көндәшлекне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планы («Юл картасы»)**

Алга таба көндәшлекне үстерү өчен 2018-2020 елларга көндәшлекне үстерүгә ярдәм итү буенча чараларны тормышка ашыру («юл картасы») буенча ведомство планы төзелгән (Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 гыйнварындагы 4-п номерлы Карары белән расланган).